ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ӘЛМӘНДӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2025 ел, 17 февраль N 150

Зур Куккуз авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль контроль хакындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Зур Куккуз авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Зур Куккуз авыл җирлеге Советының 2021 елның 11 октябрендәге 48 номерлы карары белән расланган Зур Куккузр авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.18 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1)контроль чара актын рәсмиләштергәннән соң контрольдә тотыла торган затка, аларны бетерү срокларын күрсәтеп, мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә, шулай ук контроль төре турында федераль законда каралган башка чараларны бирергә;»;

3.3 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктлары нигезендә уздыру очракларыннан тыш, планнан тыш документар тикшерү бары тик прокуратура органнары белән килештереп кенә үткәрелергә мөмкин. ";

3.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле өченче абзац өстәргә:

«"Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктлары нигезендә уздыру очракларыннан тыш, планнан тыш күчмә тикшерү бары тик прокуратура органнары белән килештереп кенә үткәрелергә мөмкин. ";

3.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац өстәргә:

"Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктлары нигезендә уздыру очракларыннан тыш, рейд тикшерүе бары тик прокуратура органнары белән килештереп кенә үткәрелергә мөмкин.”.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районының
Зур Куккуз авыл җирлеге башлыгы урынбасары,
Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районының
Зур Куккуз авыл җирлеге Советы Рәисе А.Г.Ибрагимов